

Жирдә матур урыннар күп. Аларнын һәркайсы үз тарихын, анын үз хезмәтләре, гамәлләре белән кешеләр үзләре яза. Теников районы Ишейки авылын якташлары данлый. Аларнын берсе - 30 ел «ВИСХАГИ» ны житәкләгән Зариф Закир улы Еникеев турында сүз.
Зариф Закир улы Ишейки авылында 1932 елда крестьян гаиләсендә туа. Жидееллык мәктәпне тәмамлагач, авыл хужалыгы техникумына укырга керә. Аннан армиядә була. Дүрт ел Балтыйк флотында хезмәт итеп кайткач, Зариф Закир улы «Землеустройство» белгечлеге буенча техникум тәмамлый. Аннан сон, СССР Авыл хужалыгы министрлыгы юлламасы буенча, Урта Азиягә «Сельхозаэрофотосъемка» предприятиесенә эшкә жибәрелә.
З.З.Еникеев һәрвакыт үз һонәренә туг-ры булып кала. Житештерүдән аерылмыйча гына, Целиноград авыл хужалыгы институтын тәмамлый. Гади техниктан проект бюросы начальнигына, ә аннан сон - кыр эшләре буенча баш белгечкә кадәр үсә. Кырык ике яшендә ана Ленинградта «Севземкадастрсъемка»ны жи-тәкләргә тәкъдим итәләр. Ун елдан сон ана РСФСРнын Атказанган землеустро-ителе исеме бирелә. «Сельхозаэрофотосъемка» предприя-тиесе «ВИСХАГИ» Ботенсоюз авыл хужалыгы аэрогеодезик эзләнүләр ин-ститутынын Тоньяк-Конбатыш филиалы итеп үзгәртелә. Институт эшләгән елларда Россия һәм БДБ (СНГ) илләре территориясендә жир-кадастр, туфрак, геоботаник һәм башка карталар булдыра, жимерелгән геодезия челтәрләрен торгызуда, чирәм жирләрне тошерүдә, жирләрне планлы материал белән тәэмин итүдә катнаша, шулай ук Монголия, Ливия, Алжир, Литва, Латвия, Эстониядә картографик эшләр башкара. Бу институт белән якташыбызнын киләчәк тормышы да бәйле.
«Теодолит һәм тахеометр белән (без аларны «ТТ» дип атый идек) мин шәхсән үзем ботен Балтыйк буе һәм ярты Европаны уздым, - дип искә ала якташыбыз. - СССР һәм РСФСР белән чиктәш дәүләтләрнен административ чикләрен ачыкладык. Ул чакта без жир үлчәүчеләр идек, ә хәзер - кадастр инженерлары, әмма анын асылы шундый: без жирне тәртипкә салдык, карталар тозү очен мәгълүмат жыйдык».
Ел саен ул Ишейкада булып, ата-аналары каберенә йори, Искә алу кичәләре оештыра, авылда яшәүче туганнарынын хәлен белешә, иптәшлә-ре белән очраша. Анын кече Ватанына монәсәбәте якташларына ярдәм итүендә дә чагыла. Күп кенә чыгарылыш  курс

студентлары - землеустроительләр «ВИСХАГИ»да практика узалар, ә аннары ботен Россия буенча урнашкан объектларда эшлиләр. Ул гомере буе vз эшенә бирелгән, анын vсеше белән шогыльләнгән. Белем артыннан хәтта чит илгә дә барган.
З.З.Еникеев зур һәм бәхетле тормыш кичерә. Анын янәшәсендә һәрвакыт анын гаиләсе була. Бvген ул лаеклы ялда. Санкт-Петербургта яши.
- Мина инде туксанынчы ел китте, - ди Зариф Закир улы. - Тик мин әлегә кадәр хезмәттәшләремә барлык мәсьәләләр буенча консультация бирәм. Унышым-нын сере нидә дип сорасагыз - хезмәт союченлектә генә дип саныйм. Монын очен әти-әниемә зур рәхмәт. Бvген бу бик моһим.
Темниклылар vзләренен кече Ватаннары очен дан казанган якташлары белән горурланалар. Аны дәvләт тә югары бәяләде: житәкче вазифасында озак еллар намуслы хезмәте очен Зариф Закир улы Еникеев Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Халыклар Дуслыгы ордены, «За преобразование Нечерноземья РСФСР» медале, СССР ВДНХнын алтын һәм комеш медальләре һәм башка бvләкләр белән бvләкләнгән якташларыбызнын берсе ул.

**Наилә НАСЫРОВА**